**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«28» февраль 2020 ел № 45/2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 октябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 32/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4.1 өлеше, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 октябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 32/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның исемендә һәм 1 пунктында «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләренә алыштырырга;

1.2. әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенең исемендә, 1 һәм 2 пунктларында «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Сәмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Совет СЕМЕКЕЕВСКОГО сельского поселения

И.М.Усманов